# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы Лаеш районы буенча**
**Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының**
**суд участоклары чикләре турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 23 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Лаеш районы буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре тасвирламасын әлеге Законга кушымта нигезендә расларга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2010 елның 31 декабре
№ 116-ТРЗ

"Татарстан Республикасы Лаеш районы буенча
Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының
суд участоклары чикләре турында"
Татарстан Республикасы Законына
кушымта

**Татарстан Республикасы Лаеш районы буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре тасвирламасы**

**1 нче суд участогы**

1 нче суд участогы чигенә түбәндәге муниципаль берәмлекләр территорияләре керә: Лаеш муниципаль районының Атабай, Олы Кабан, Габишев, Хәерби, Макаровка, Матюшино, Нармонка, Никольский, Орел, Комлы Кавал, Рождествено, Столбище һәм Татар Сараланы авыл җирлекләре.

**2 нче суд участогы**

2 нче суд участогы чигенә түбәндәге муниципаль берәмлекләр территорияләре керә: Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре, Александровка, Державино, Егорьево, Көек, Кече Елга, Пәрәү, Сокуры, Урта Девятово, Татар Янтыгы һәм Чырпы авыл җирлекләре.